КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 19 июль г.Казань № 534

2025 – 2027 елларга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2025 елга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләренең 18 239 463,15051 мең сум күләмендә программасын;

2025 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында Казан шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 2 000 000,0 мең сум күләмендә финанслана торган программаны;

2025 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында Чаллы шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 1 360 000,0 мең сум күләмендә финанслана торган программаны;

2025 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында Түбән Кама шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 480 000,0 мең сум күләмендә финанслана торган программаны;

2025 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлауга юнәлдерелгән, 1 396 600,0 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

2025 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында автомобиль юлларын һәм ясалма юл корылмаларын норматив хәлгә китерүгә юнәлдерелгән, федераль бюджеттан 7 101 917,1 мең сум күләмендә субсидия рәвешендә кергән акча һәм 1 887 851,5 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

2025 елга «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасындагы «Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» ярдәмче программасының гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәреннән авыл торак пунктларының иң якын иҗтимагый әһәмиятле объектларына, шулай ук авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү объектларына алып бара торган каты өслекле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм реконструкцияләү чараларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән, федераль бюджеттан 818 023,6 мең сум күләмендә субсидияләр рәвешендә кергән акча һәм 217 449,4 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

2025 елга Татарстан Республикасының терәк торак пунктларында юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерүгә юнәлдерелгән программаны 11 163 134,619 мең сум күләмендә;

2025 елга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасын тормышка ашыру кысаларында коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек берләшмәләренә керү юлларын капиталь ремонтлауга, ремонтлауга юнәлдерелгән 300 000,0 мең сум күләмендәге программаны;

2026 елга Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы юлларында 22 496 918,5 мең сум күләмендә юл эшләре программасын;

2026 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында Казан шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 2 000 000,0 мең сум күләмендә финанслана торган программаны;

2026 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында Чаллы шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 1 360 000,0 мең сум күләмендә финанслана торган программаны;

2026 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында Түбән Кама шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 480 000,0 мең сум күләмендә финанслана торган программаны;

2026 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлауга юнәлдерелгән, 1 396 600,0 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

2026 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында автомобиль юлларын һәм ясалма юл корылмаларын норматив хәлгә китерүгә юнәлдерелгән, федераль бюджеттан 9 991 305,6 мең сум күләмендә субсидия рәвешендә кергән акча һәм 3 695 414,5 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

2026 елга «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасындагы «Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» ярдәмче программасының гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәреннән авыл

торак пунктларының иң якын иҗтимагый әһәмиятле объектларына, шулай ук авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү объектларына алып бара торган каты өслекле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм реконструкцияләү чараларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән, федераль бюджеттан 359 164,8 мең сум күләмендә субсидияләр рәвешендә кергән акча һәм 132 841,8 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

2027 елга Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы юлларында 21 056 456,1 мең сум күләмендә юл эшләре программасын;

2027 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында Казан шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплексны үстерү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 2 000 000,0 мең сум күләмендә финанслана торган программаны;

2027 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында Чаллы шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплексны үстерү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 1 360 000,0 мең сум күләмендә финанслана торган программаны;

2027 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында Түбән Кама шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплексны үстерү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 480 000,0 мең сум күләмендә финанслана торган программаны;

2027 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлауга юнәлдерелгән, 1 396 600,0 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

2027 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында автомобиль юлларын һәм ясалма юл корылмаларын норматив хәлгә китерүгә юнәлдерелгән, федераль бюджеттан 13 494 354,7 мең сум күләмендә субсидия рәвешендә кергән акча һәм 6 646 473,3 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

2025 елга Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы юлларда юл эшләренең гомуми суммасы 47 870 173,75851 мең сум тәшкил итә, шул исәптән юл эшләрен башкаруга Татарстан Республикасы бюджетыннан «Юл эшләре программаларын финанслау дирекциясе» дәүләт бюджет учреждениесенә бирелгән 2 905 734,389 мең сум күләмендә субсидия акчалары;

Татарстан Республикасы Юл фондының Татарстан Республикасы исеменнән төзелгән товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт контрактлары өчен түләүгә юнәлдерелгән, 2024 елда шушы дәүләт контрактлары шартлары нигезендә түләнергә тиешле калган акчалары суммасы 2025 елның 1 гыйнварына торышына 4 412 395,58205 мең сум тәшкил итә;

2026 елга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләренең гомуми суммасы 41 912 245,2 мең сум тәшкил итә дип билгеләргә;

2027 елга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләренең гомуми суммасы 46 433 884,1 мең сум тәшкил итә дип билгеләргә.

3. Җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы юлларда муниципаль юл эшләре программаларын гамәлгә ашыруга җибәрелә торган муниципаль юл фондларының ассигнованиеләре күләме турында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре тәкъдимнәрен кабул итәргә:

2025 елга 1 нче кушымта нигезендә 1 670 456,7 мең сум күләмендә;

2026 елга 2 нче кушымта нигезендә 1 731 529,7 мең сум күләмендә;

2027 елга 3 нче кушымта нигезендә 1 785 380,7 мең сум күләмендә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2025 елга Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре турында» 2025 ел, 21 февраль, 107 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы юлларда юл эшләре турында» 2025 ел, 21 февраль, 107 нче карары белән расланган «Яшәү өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында Түбән Кама шәһәре агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплексы үстерү программасына үзгәреш кертү хакында» 2025 ел, 7 апрель, 200 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре турында» 2025 ел, 21 февраль, 107 нче карары белән расланган «Яшәү өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында автомобиль юлларын һәм ясалма юл корылмаларын норматив хәлгә китерүгә юнәлдерелгән программага үзгәреш кертү хакында» 2025 ел, 10 май, 308 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре турында» 2025 ел, 21 февраль, 107 нче карары белән расланган «Яшәү өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында автомобиль юлларын һәм ясалма юл корылмаларын норматив хәлгә китерүгә юнәлдерелгән программага үзгәреш кертү хакында» 2025 ел, 17 июнь, 440 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре турында» 2025 ел, 21 февраль, 107 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 ел, 25 июнь, 458 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин